| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» 03 2023 ел № 126

Торак урынның бер квадрат метрының уртача исәп-хисап базар бәясен куллану турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыкның эксперт-консультация советының 2023 елның 21 февралендәге 67 номерлы хаты һәм торак комиссиясенең 2023 елның 30 мартындагы 5 номерлы карары нигезендә, Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзаларының яисә ялгыз яшәүче гражданның милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү өчен торак урынның бер квадрат метрының уртача исәп-хисап базар бәясен 22650 сум күләмендә кулланырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов